РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

«_13_» _ноябрь__ 2025 ел №_13__

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендәге өченче затлар хокукларыннан азат (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген раслау турында» 2017 елның 13 декабрендәге 130 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Чирмешән муниципаль районы территориясендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм инфраструктурасын төзүче оешмаларга мөлкәти ярдәм күрсәтү максатларында «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 32 статьясындагы 2 өлешенең 25 пунктына таянып, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендәге, өченче затлар хокукларыннан азат (кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлеген раслау турында» 2017 елның 13 декабрендәге 130 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы

карарына (район Советының 2018 елның  13 декабрендәге 199 номерлы, 2019 елның 14 ноябрендәге 252 номерлы, 2019 елның 13 декабрендәге 260 номерлы, 2020 елның 13 мартындагы 272 номерлы, 2020 елның 28 августындагы 294 номерлы, 2023 елның 09 ноябрендәге 211 номерлы, 2024 елның 12 ноябрендәге 273 номерлы, 2025 елның 06 июнендәге 312 номерлы карары белән кабул ителгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендәге, өченче затлар хокукларыннан азат һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлегенә 1 нче кушымта нигезендә күчемсез мөлкәт объекты өстәргә.

1.2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендәге, өченче затлар хокукларыннан азат һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлегеннән күчемсез мөлкәт объектларын 2 нче кушымта нигезендә төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Безнең Чирмешән» («Наш Черемшан») район газетасында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисади мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов

1 нче кушымта

РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2025 елның 13 ноябрендәге 13 номерлы карары белән

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендәге, өченче зат хокукларыннан азат һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән муниципаль мөлкәт исемлегенә өстәмә

| № п/п | Мөлкәт исеме | Мөлкәтнең урнашу урыны | Мәйданы (кв.м.) |
|---|---|---|---|
| 1 | 1 нче бинаның өлеше («Караван Сарай» сәүдә үзәге бинасы коридорының 1 катында) | Татарстан Республикасы, Чирмешән районы, Чирмешән ав., М.Титов ур., 22А й. | 10 |

Районның Мөлкәт һәм
җир мөнәсәбәтләре палатасы
рәисе вазыйфаларын башкаручы Гераева Н.М.

2 нче кушымта

РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2025 елның 13 ноябрендәге 13 номерлы карары белән

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы милкендәге, өченче зат хокукларыннан азат һәм кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән, исемлектән төшереп калдырылырга тиешле муниципаль мөлкәт

| № п/п | Мөлкәт исеме | Мөлкәтнең урнашу урыны | Мәйданы (кв.м.) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 нче бинаның өлеше («Караван Сарай» сәүдә үзәге бинасының 2 нче катында) | Татарстан Республикасы, Чирмешән районы, Чирмешән ав., М. Титов ур., 22А й. | 59,0 |
| 2 | Бина («Безнең Чирмешән» район газетасы редакциясе бинасының 1 катында) | ТР, Чирмешән районы, Чирмешән ав., Беренче Май ур., 27 й. | 42,6 |

Районның Мөлкәт һәм
җир мөнәсәбәтләре палатасы
рәисе вазыйфаларын башкаручы Гераева Н.М